БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«______» ________ 2020 ел №______

**Балтач муниципаль районында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга торак урыны бирү нормасы һәм мәйданның хисап нормасы турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Балтач муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Билгеләргә:

1.1. торак урынның мәйданының хисап нормасын, шуннан чыгып, торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында гражданнарның торак урыннары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе билгеләнә, гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданының 18 квадрат метрыннан кимрәк күләмдә;

1.2. торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга бирелә торган торак урыны гомуми мәйданының минималь күләмен билгеләгәндә кулланыла торган, түбәндә күрсәтелгән күләмдәге торак урыны бирү нормасын:

- Торак бинаның гомуми мәйданының 33 квадрат метры - бер кешегә;
- Торак бинаның гомуми мәйданының 42 квадрат метры - ике кешедән торган гаиләгә;
- Гаиләнең һәр әгъзасына торак бинаның гомуми мәйданының 18 квадрат метры - өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаиләгә.

2. Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Балтач муниципаль районында торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен торак урын мәйданының хисап нормасы турында» 2006 елның 24 гыйнварындагы 7а номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының карарын;

- «Балтач муниципаль районы буенча торак бирүнең исәп-хисап нормасы турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 10а номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының карарын.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов